**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлегенең Бәрлегуҗа авылында 2025 елда гражданнардан үзара салым кертү турында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**2024 елның 26 ноябре** **№5**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Бәрлегуҗа авылындагы гражданнар җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлегенең Бәрлегуҗа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге территориясендә турыдан-туры яшәүче, ташламалы категорияләрдән (беренче төркем инвалидлар, көндезге формада укучы студентлар, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары) тыш, тавыш бирү хокукына ия яшәү урыны буенча теркәлгән ,бәлигъ булган һәр гражданнан 2025 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлегенең Бәрлегуҗа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге территориясендә турыдан-туры яшәүче, ташламалы категорияләрдән (беренче төркем инвалидлар, көндезге формада укучы студентлар, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары) тыш, тавыш бирү хокукына ия ,яшәү урыны буенча теркәлгән ,бәлигъ булган һәр гражданнан 2025 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.

«РИЗА" "КАРШЫ"

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат такталарында урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Карамалы ав., Үзәк ур., 4 й.

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Бәрлегуҗа авылы, Тукай ур., 16 йорт, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районының Олы Карамалы авыл җирлеге башлыгы ,
гражданнар жыенында рәислек итүче: Э.И.Байдамшин